**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы, 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

“21” ноябрь 2024 ел. № 33

**Әтнә муниципаль районы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында”гы 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 05.09.2024 ел, № 731 карары нигезендә, район халкының тормыш сыйфатын яхшырту максатларында һәм Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф ставкаларын (окладларын) күтәрү кирәклегенә бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Кушымта нигезендә Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентларын һәм тариф ставкаларын (окладларын) арттырырга.
2. Әтнә муниципаль районы башлыгының 2024 елның 8нче маендагы 4нче номерлы « Әтнә муниципаль районы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф. И. Гыймадиевка йөкләргә.

Башлык вазыйфаларын башкаручы: А.Ф. Каюмов

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы карарына кушымта
«21» ноября 2024ел № 33

Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең бердәм тариф челтәре буенча тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәре өчен түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сумнар |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 21200 |
| 2 | 1,0114 | 21442 |
| 3 | 1,0233 | 21694 |
| 4 | 1,0346 | 21934 |
| 5 | 1,0473 | 22203 |
| 6 | 1,0595 | 22461 |
| 7 | 1,0728 | 22743 |
| 8 | 1,0855 | 23013 |
| 9 | 1,0983 | 23284 |
| 10 | 1,1119 | 23572 |
| 11 | 1,1251 | 23852 |
| 12 | 1,1393 | 24153 |
| 13 | 1,1535 | 24454 |
| 14 | 1,1675 | 24751 |
| 15 | 1,1823 | 25065 |
| 16 | 1,1973 | 25383 |
| 17 | 1,2124 | 25703 |
| 18 | 1,2280 | 26034 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклад) күләме җитәкченең тариф ставкасыннан (оклад) 1-2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.